Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Мәмәт авыл Башкарма комитеты

КАРАР

23 январь 2024 ел № 1

Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, Әлмәт районында 2024 елның 18 январендагы 51-34-09/143 номерлы клиентлар хезмәте мөрәҗәгате (бүлек хокуклары) нигезендә

Мәмәт авыл башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2024 елның 01 февраленнән Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1, 2 нче кушымталарга ярашлы рәвештә 8370,20 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл Башкарма комитетының «Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен билгеләү турында» 2023 елның 14 сентябрендагы 1 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Әлмәт районы, Мәмәт авылы, Совет урамы, 1 йорт, Чупай авылы Совет урамы, 43А йорты, Сәмәрканд бистәсе, Үзәк урамы, 1 нче йорт адресы буенча урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка игълан итәргә, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайты «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 01 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Мәмәт авыл Башкарма
Комитеты җитәкчесе Х.М.Бәдгетдинова

Әлмәт муниципаль районы
Мәмәт авыл Башкарма комитетының
2024 елның «23» январендәге
1 номерлы карарына 1 нче
кушымта

Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлеге территориясендә
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән
исемлеге бәясе

| №№ п/п | Хезмәтләр исемлеге | Хезмәтләр бәясе, сумнарда. |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләүләр өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Гроб, җирләү өчен кирәк булган башка предметлар бирү | 4 873,92 |
| 3 | Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка алып килү | 785,63 |
| 4 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 710,65 |
| Барлыгы | | 8 370,20 |

Мәмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Х.М.Бәдгетдинова

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «МАМЕТЬЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ОГРН 1061644004784
Р.05-10986/16
МАМЕТЬЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1644036569
КПП 164401001

Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл Башкарма комитетының 2024 елның «23» январендәге 1 номерлы карарына 2 нче кушымта

Әлмәт муниципаль районы Мәмәт авыл җирлеге территориясендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| №№ п/п | Хезмәтләр исемлеге | Хезмәтләр бәясе, сумнарда |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Җирләүләр өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2 | Гәүдәне төрү | 2 857,57 |
| 3 | Гроб, җирләү өчен кирәк булган башка предметлар бирү | 2 016,35 |
| 4 | Үлгән кешенең гәүдәсен (мәетен) зиратка алып килү | 785,63 |
| 5 | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 2 710,65 |
| Барлыгы | | 8 370,20 |

Мәмәт авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Х.М.Бәдгетдинова

МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «МАМЕТЬЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ» АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ОГРН 1061644004784
Р.05-10986/16
МАМЕТЬЕВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ИНН 1644036569
КПП 164401001